БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре №130

Баулы шәһәр Советының 2023 елның 25 маендагы 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2023 елның 25 маендагы 97 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына (2024 елның 12 апрелендәге 123 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2. 1 пунктны түбәндәге пунктча белән тулыландырырга:

«8) физик затларда җирле салымнар буенча, Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң, 500 сумнан артмаган суммада бурычлар булу.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында bavly.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров